# Минзэлэ
# муниципаль районы
# ***Наратлы-Кичу***
# авыл жирлегенен
# отчеты

2016 ел

**Хэерле кон, хормэтле Айдар Фаслахович!**
**Хормэтле жирлегебез депутатлары, авылдашлар, килгэн кунаклар!**

Буген без Наратлы-Кичу авыл жирлегенен 2016елнын еллык отчеты унаеннан жыелдык.

Бугенге отчет жыелышында катнашалар:

Минзэлэ муниципаль район башлыгы Салахов Айдар Фаслахович.

Мензелинские зори агрофирмасынын ООО Калинин булекчэсенен житэкчесе Акберов Ильдар Ахтямович

Һэм Минзэлэ муниципаль районы оешма житэкчелэре.

Бугенге жыелышнын кон тэртибе:

1. Авыл жирлегенен 2016 елнын отчеты.
2. Участок полициясенен отчеты.
3. Мензелинские зори агрофирмасынын ООО Калинин булекчэсенен житэкчесе Акберов Ильдар Ахтямович чыгышы
4. Ветераннар советы житэкчесенен чыгышы -
5. Минзэлэ муниципаль район башлыгы Салахов Айдар Фаслахович чыгышы.

Беренче кон тэртибе буенча сузне уземэ алам.

Наратлы-Кичу авыл жирлеге территориясенэ 3 авыл урнашкан : Наратлы-Кичу, Шикарле-Каен, Исангул 2017 елның 1 январена алынган мәгълуматлар буенча

| Ел башына җирлектэ яшәүчеләр | **2014 год** | **2015 год** | **2016 год** | **2017 год** |
|---|---|---|---|---|
| | **465** | **465** | **462** | **451** |
| **в т.ч. Татарлар** | **448** | **448** | **447** | **438** |
| **Руслар** | **7** | **7** | **7** | **5** |
| **әрмәннәр** | **9** | **9** | **7** | **7** |
| **узбәк** | **1** | **1** | **1** | **1** |

Шунын эченнэн җирлектэ 154 пенсионер, 19 инвалид бар.

Эш яшендэ 237 кеше, 41 бала яши.

Бюджет учреждениелэрендэ барлыгы 19 кеше эшли.

Шуларнын 2 се Хужэмэт мэктэбенэ йореп эшли.

Наратлы-Кичу авыл жирлегендэ эшлэуче 78 кеше, ООО Калинин оешмасында эшлэуче 35 кеше яши. 72 кеше башка шэһэрлэргэ һэм авылларга йореп эшли.

Безнен авыл җирлегендэ кошчылык комплексы ачылды

Ул җирлектәге халыкны эш белэн тэмин иту өчен унайлы. Анда безнен 10 кеше эшли.

Жирлектэ барлыгы 209 хужалык бар.
Безнен җирлектэ халык эре могезле терлек асрау белэн шогыльлэнэ .
Купчелеге сыер асрап сот һәм ит сата.
Шэхси хужалыкларда бугенге кондә

| | **На 01.01.2014 г.** | **На 01.01.2015 г.** | **На 01.01.2016 г.** | **На 01.01.2017г.** | **+ / -** |
|---|---|---|---|---|---|
| КРС | 612 | 686 | 685 | 696 | +11 |
| в т.ч. коровы | 236 | 273 | 290 | 295 | +5 |
| свиньи | 0 | 0 | 0 | 20 | +20 |
| овцы, козы | 256/8 | 223/12 | 333 / 20 | 245/20 | -88 |
| птицы | 1600 | 1500 | 1 600 | 1500 | -100 |
| пчелосемьи | 50 | 70 | 70 | 76 | +6 |

Безнен авыл җирлегендэ бик тырыш кешелэр яши. Мал асрау өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

Хөкүмәтебез сыер асраучы хуҗалыкларга сыер башына 3мең сум күләмендә субсидия бирде. Җирлектә 295 сыерга 885мен сум, 16 кэжэгэ 16 мен сум, 12 баш атка 36 мен сум, 400 баш кошка 36700 сум субсидия алынды. Мини фермалар програмалары буенча 3 хужалык 200 мен субсидия алдылар.

Авыл җирлегендә 4 КФХ бар

Менә мәсәлэн Бикбаев Анвар 15 сыер , Мингазов Рәзим КФХ -10 сыер, Мингазов Хайдар-11 сыер, КФХ Валиев Минненаил -30 сыер асрый.

КФХ булмаган шәхси хуҗалыкларда да сыерны бик куп асрыйлар. Мәсәлән, Сафиуллин Азат 8 баш сыер, Мингазов Халит-5баш сыер. Ахметшин Айдар-15баш сыер,Курбанов Фарит-5баш сыер, Абдуллин Рэис-5 баш, Мингазова Гөлфия 5баш сыер, Марданова Айгулнен-5 баш сыер, Садыйков Расим 4баш сыер, Хабибрахманов Хайдар-4баш сыер, Каюмов Рушан -5 сыер, , Бадрутдинов Фаил-8 баш сыер, Нуретдинов Рашит -5 сыер.Исәнгол авылыннан Гиниятуллин Флус 5сыер, Шайхутдинов Наил -10 сыр, Гиниятуллин Фәнис -7сыер,Газизова Фатима -8сыер. Сыер булгач анын бозавы да була, куплэп угез,тана асрыйлар.

Олы мал тоту белэн берлектэ безнен авыл жирлегендэ кош-корт асрау да киң җәелгән. Мәсәлән Мингазов Халит хуҗалыгында 100 куркә, 100 каз, Мингазов Фарахетдин хуҗалыгында 110 каз , 200 бройлер чебие, Набиуллина Энҗе 100 каз, 100 бройлер чебие. Хатыйпова Махтума 100 каз, 200 бройлер, Сафиуллина Диляра 100 каз, 70 урдэк, 100 бройлер чебие, Мингазов Хайдар 100 каз, 150 бройлер чебие, Курбанов Фарит 100баш урдәк, 100 баш бройлер чебие

Калган хуҗалыкларда да 50-60 баштан да ким кош-корт асрамыйлар.

Авыл халкы жэй коне узенэ җитәрлек печәнне үз көче белән чабып өеп куйдылар.

Бадрутдинов Фаил, Мингазов Разим , Гиниятуллин Флус, Абдуллин Раис, Курбанов Фарит, Мингазов Хайдар, Мингазов Халит, Валиев Ирек үз тракторлары белән печән чабу,рулонга салу, алып кайту эшләрен башкаралар.

Мал асрау өчен һәр хуҗалык узенә җитэрлек куләмдә фураж сатып алды, әзерләде.

Пай җирлэре тулысынча рәсмиләштерелеп бетерелгән. 6 кеше 205 ,4 га пай җирләрен алып үзләре эшкәртеп печәнґ, салам, фураж житештерәләр.

Наратлы-Кичу авыл җирлеге буенча 2977,6 га пай җире рәсмиләштерелеп "Мензелинские зори" агрофирмасының Калинин булекчәсенә арендага бирелде.

Пай җирләре өчен август аенда халык 2,5 ц. исәбеннән фураж алды. Лэкин бу тулысынча түләнеп бетерелмэгэн, тагын 2,5 ц. фураж түлиселәре калды.

Востребованный фондта 261 пай исэплэнә.Невостребованный фондта-117 пай исәпләнә, шунын эченнэн 26 пай суд аша район хисабына кучте , 16 пай авыл советы хисабына кучте.

Авыл жирлегендэ бер хужалыкка 318710 сум керем туры килэ. Барлыгы 85 тонна ит, 1576 тонна сот житештерелә һэм шуның 1076 тоннасы сатылды.

Халыкка узеннән арткан продукцияне сату момкинлеге тудырылган. Буген сөт җыю буенча проблема юк .Безнен авыл җирлегендә сөт җыю белән 2 кеше - Табанаков Сергей, Валиев Минненаил шөгыльлэнә, акчасын вакытында тулэп баралар.

Районыбызда һәм Чаллы шәһәрендә ярминкәләр оештырыла.

Авыл халкы узеннең җитештергән продукциясен шунда алып барып сата.

Җирлектә **налоглар**

***Жирлек буенча 290 мен сум налог жыю планда каралган иде.***
**Үтәлеше - 362 мен сум 125% ка үтәлгән.**

Молкэт өчен налог план буенча- 32 мен , чынлыкта 46 мен жыелды. Бу 145% тэшкил итэ.

Жир өчен налог план буенча 237 мен, чынлыкта 232 мен жыелды. Бу 98% тэшкил итэ.

НДФЛ буенча 20 мен чутланган, 77 мен сум жыелды. 385% утэлеш.

**Наратлы-Кичу авыл җирлеге буенча 2015 ел өчен узара салым акчасы 57000 сум күләмендә җыелды, 285 мен күләмендә республикадан акча алынды. Шул акчанын 245 меңе Наратлы-Кичу авыл зиаратын профнастил койма белән әйләндереп алуга тотылды, калган 40 меңенә 3 авыл зиаратына туалет һәм чүп җыю өчен контейнерлар куелачак.**

**2016 елда 74411 сум күләмендә узара салым акчасы җыелды.Хокумәт акчасын кушкач ул 372 мен сум була .Әлеге акчалар Шикәрле-Каен авылында пожарный гидрант урнаштыру өчен һәм дә Наратлы-Кичу авыл урамнарына яктырткыч утлар кую өчен тотылачак.**

2017 елда җыелачак узарасалым акчасына Исангол авыл урамына яктырткыч утлар кую планлаштырыла. Шикарле-Каен авылының су башнясынын түбәсен ябуга һәм

Наратлы-Кичу авылынын зиаратын зурайтуга тотылачак.

**Хөкүмәтебез авыл хуҗалыгы тармакларын устерү, халыкнын яшәешен яхшырту максатыннан кабул иткән программаларның берничәсе безнең җирлеккә дә кагылды.**

Кечкенэ авылларнын юлларын яхшырту программасы нигезендэ Шикарле-Каен авылына хэтле 1200 м юл салынды.

Шулай ук Шикарле-Каен авылында тулысынча электр баганалары һәм электр линияләре алыштырылды, баганаларга яктырткыч утлар куелды.

Җирлектә август аеннан бирле һәр атнаның җомга конендә "Чиста шәһәр" оешмасынан килеп капчыкка тутырылган чүпләрне җыеп алып китәләр. Кыш көнендә бу эшләр ике атнага бер тапкыр башкарыла. Һәр хуҗалык ихатасындагы чупне чыгырырга тиеш була. Мин яндырам, минем чүбем юк дигән сылтаулар кабул ителми, яшәгән җирдә чүп булмый калмый.

Иртә яздан алып көзгә кадәр авыл җирлегендә өмәләр оештырыла.

Һәр бюджет хезмәткәрләре үзләренең бина кырыйларын җыештыра, юл буйларын чаба,чүп җыя,Наратлы-Кичу авылы фермасына өмәләргә бара.

Бөек Ватан сугышында яу кырында ятып калган авылдашлар хормэтенэ куелган обелиск яннарын чистартып, агартып, чәчәкләр утыртып торабыз.

Авыл җирлегендә 2 кибет бар. Кибетнең берсе ПО "Алабуга" карамагында, югары очтагы кибет шәхси эшмәкәр Буранов Альбертныкы.Кибетләрдә яна ипи, яшелчә, җиләк-җимеш, көнкүреш кирәк –яраклары сатыла, халык канәгать. Аракы сатучы барлык нокталарга да ЕГАИС куелган.

Шулай ук авылда 1 башлангыч мэктэп бар, анда 5 бала укый. Балалар бакчасы бар, анда 8 бала тэрбияләнә. Бер почта булекчәсе эшли.

2015 елда Наратлы-Кичу авылында купфункцияле үзәк ачылды. Анда Мәдэният йорты, китапханә, фельдшер-акушерлык пункты, авыл советы урнашкан.

Күптән көтелгән җылы мәдәният бинасында төрле чаралар үткәрелә. Аеруча истә калганнары

-Чаллы язучылары белән очрашу,Габдулла Тукайның тууына 130 ел тутуга багышланган әдәби музыкаль - кичә,

-9 май бәйрәме, Сабан туй,

- өлкәннәр көне зурлап үткәрелде.

-яна ел бэйрэме бик күңелле узды. Шулай ук сирәгрәк булса да артистлар да килеп тора. Соңгы вакытта Нефтекама шәһәреннән килгән артистлар бик күңелле концерт күрсәттеләр.

Китапханәдә һәр юбилей һәм истәлекле даталар билгеләп утелә. Китап күргәзмәләре, кичәләр оештырыла. Китап яшьлекне туендыра, ә картлыкның күңелен күтәрә,ди. Шуңа күрә балаларыбыз китапханәдән тулысынча файдаланасын, ә картларыбыз үзләренен күңелләренә хуш килгән китапларны укып күнелләрен күтәрсеннәр.

Хәзерге көндә Наратлы-Кичу авыл җирле Советында 7 депута план нигезендә эш алып баралар.

Авыл җирлегендә 2016 елда планлаштырылган 13 утырышта барлыгы 20 сорау каралды.Халыкның тормыш шартларын яхшырту, авыл җирлеге территориясендә куркынычсызлык һәм тәртип булдыру, халык өчен кирәк булган барлык социаль объектларның һәм учреждениеләрнең өзлексез эшләвен тәэмин иту,авылларны төзекләндерү максатыннан 20 карар кабул ителде һәм аларны тормышка ашыру өчен бик күп эшләр башкарылды.

Шулай ук авылның ветераннар советы белән дә эш тыгыз элемтәдә урнаштырылган.

2016 елда планлаштырылган эшләр нигездә үтәлде дип әйтәсем килә.

2017 нче елга бурычлар һәм планнар.

- Халыктан җыелган салым акчасына Наратлы-Кичу, Исангол авыллары **урамнарына яктырткыч утлар кую .**
- Наратлы-Кичу авыл урамнарын яхшырту.
- Шэхси хуҗалыкларда мал һәм кош-корт санын арттыру.

**Хөрмәтле иптәшләр!** 2016 елда сезнен белән бергәләп эшләгән эшләребезнең төп моментлары шушылар иде.
2017 елда алда торган бурычларны хәл итүдә барыбыз да бергәләп эшләрбез дип ышанам.

Суземне йомгаклап шуны эйтэсе килэ,
килэчэктэ дэ бергэ- бергэ авылларыбызны кутэру, устеру остендэ нэтижэле эш алып барырга, һэм барыбызга да исэн-сау, сэламэт яшэргэ язсын.